РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МИХАЙЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИХАЙЛОВКА ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

---

**№ 8**

с. Михайловка “28” апрель 2023г.

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 14 декабрендәге 21 номерлы «16 яше тулган балигъ булмаганнарга өйләнешергә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 26 мартындагы 236 номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә таләпләр турында» гы карарын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 14 декабрендәге 21номерлы «16 яшькә җиткән балигъ булмаганнарга өйләнешүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гарызнамәне формат һәм логик яктан тикшерү орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә бердәм портал тарафыннан автоматлаштырып, мөрәҗәгать итүченең гарызнамәнең электрон формасындагы һәрбер юлын тутыру процессында башкарыла. Бердәм портал тарафыннан электрон формадагы гарызнамә юлының дөрес тутырылмавы ачыкланса, мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерүнең тәртибе турында гарызнамәнең электрон формасының үзендә үк мәгълүмати хәбәр аркылы кисәтелә».

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны уз остемдэ калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Н.А. Ращупкина